УДК 9.929
EDN MMNYSK
DOI 10.24412/2073-7475-2026-4-91-104

Хатлар – тормыш көзгесе: Һади Атласи һәм аның нәсел варислары (Һ. Атласиның тууына 150 ел тулу уңаеннан)

Х. З. Баһаветдинова,

Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Ш. Мәрҗани исемендәге Тарих институты, Казан шәһ., Татарстан Республикасы, Россия Федерациясе

Letters as a Mirror of Life: Khadi Atlasi and His Descendants (on the occasion of the 150th anniversary of Kh. Atlasi's bith)

Kh. Z. Bagautdinova,

Institute of History named after Sh. Marjani of the Academy of Sciences of the Republic of Tatarstan, Kazan, Republic of Tatarstan, Russian Federation

Аннотация

Статья приурочена к 150-летнему юбилею ученого-историка, педагога и общественного деятеля Хади Атласи. Изучены документы, хранящиеся в Государственном архиве Республики Татарстан, ранее не введенные в научный оборот. Были проанализированы личные письма, дневники и документы об учебе его детей, представленные в фонде «Хади Атласи (Атласов Хади Мифтахутдинович (1879-1938 гг.) – историк, педагог, религиозный и общественный деятель» (Р-6800). Дополнительные сведения о Казанском периоде жизни (1934-1935 гг.) были обнаружены в фонде «Народного комиссариата просвещения ТАССР» (Р-3682). Выявлены имена единомышленников, оказывавших ему помощь. Также были использованы опубликованные научные труды. Через письма осветили жизнь, деятельность и взаимоотношения его детей. Несмотря на преследования в годы советской власти, они нашли свое призвание – окончив высшие учебные заведения служили народу.

Abstract

The article is dedicated to the 150th anniversary of the historian, teacher, and public figure Khadi Atlasi. The study examines documents from the State Archive of the Republic of Tatarstan that have not previously been introduced into scholarly discourse. Personal letters, diaries, and records of his children's education from the archival fund "Khadi Atlasi (Atlasov Khadi Miftahtubdinovich (1879-1938) – historian, teacher, religious and public figure)" (R-6800) were analyzed. Additional information regarding the Kazan period of his life (1934-1935) was discovered in the fund of the "People's Commissariat of Education of the TASSR" (R-3682). The names of like-minded individuals who assisted him have been identified. Published scholarly works were also consulted. The letters shed light on the lives, activities, and relationships of his children. Despite persecution during the Soviet years, they found their calling – after completing their higher education, they served the people.

Ключевые слова
Хади Атласи, Нижнее Чекурское, Бугульма, мулла, педагог, историк, обвинительный приговор, соратники, дети, письма, реабилитация.

Keywords
Khadi Atlasi, Nizhnee Chekurskoye, Bugulma, mullah, teacher, historian, conviction, associates, children, letters, rehabilitation.

Күренекле тарихчы-галим, мәгърифәтче, полиглот һәм җәмәгать эшлеклесе Һади Атласының (1876-1938) тууына быел 150 ел. Ул татар халкының рухи тормышында һәм тарихында тирән эз калдырган мәшһүр галим. Аның хезмәтләрендә тарихыбызның мөһим мәсьәләләре, татар мәгърифәтчелегенә карата сораулар, халкыбызның мәнфәгатьләрен чагылдырган карашлар яктыртылган.

Репрессия корбаны Атласов Һади Мифтахетдин улының тормыш юлын, фәнни-сәяси эшчәнлеген XX йөзнең 80 еллары ахырында өйрәнә башладылар. Тарихчы галимнәребез Я. Г. Абдуллин[1], М. Г. Госманов[2], И. Р. Таһиров, Б. Ф. Солтанбәков[3], С. Х. Алишев[4], Ә. Г. Кәримуллин[5], А. Л. Литвин[6], Д. М. Госмановаңың[7] фәнни мәкаләләре; укучылары – В. Хаҗиев[8], Ә. Каюмова[9]; журналист Д. Асылов[10] һәм улы Угыз Атласов язган истәлекләр басылып чыкты[11]. А. Х. Мөхәммәтдинова «Хади Атласи как историк» дигән темага кандидатлык диссертациясе яклады[12]. «Җыен фонды» бастырган «Һади Атласи: тарихи-документаль җыентык» хезмәтендә авторның «Шура», «Мәктәп» журналларында басылып



Һ. М. Атласовның паспорт кенәгәсе. 1918 елның 13 мае // Татарстан Республикасы Дәүләт архивы, Р779 ф., 3 тасв., 33 эш.

Passport book of Kh. M. Atlasov. 1918, May 13 // State Archive of the Republic of Tatarstan, fund R779, series 3, file 33.



Һ. Атласының апасы Халимә белән язышкан хатлары. Татарстан Республикасы Дәүләт архивы, Р6800 ф., 1 тасв., 2 эш, 1 икенче ягы – 3 кгз.

Correspondence between Kh. Atlasi and his sister Khalima. State Archive of the Republic of Tatarstan, fund R6800, series 1, file 2, p. 1 reverse side – 3.

чыккан мәкаләләре, суд документлары, шәхси хатлар һәм фәнни мәкаләләр урын алды[13]. Матбугатта Һ. Атласының нәсел шәҗәрәсенә кагылышлы мәкаләләр дә басылып чыкты[14].

Язмабызның максаты – укучыны Һ. Атласының Татарстан Республикасы Дәүләт архивында сакланган чыганаклар белән таныштыру, хатлар аша балаларының тормышын, эшчәнлеген, үзара мөнәсәбәтләрен күрсәтү[15].

Фондта шәхси, гаилә документлары, хатлар җыелмасы, шәхси көндәлекләр, балаларының уку турында белешмәләре, фотолар сакланган. Алар җәмәгате Хөсникамал һәм улы Угыз Атласов ярдәмендә сакланып калганнар. Угыз Атласовның кызы Әлфия Атласова Татарстан Республикасы Дәүләт архивына тапшырган*.

Чыганакларның күп өлешен гаилә документлары тәшкил итә. Хатларның күбесе иске татар телендә (гарәп графикасында) язылган.

Татарстан АССРның Чистай кантоны революцион трибуналы фондында (Р-779) Һ. Атласины контрреволюциядә гаепләү эш кенәгәсе сакланган. Сорау алу протоколлары белән аның шәхси документлары, фотосурәтләре дә бар[16].

Һ. М. Атласов 1876 елның 29 августында Сембер губернасы Түбән Чәке авылында (хәзерге Татарстан Республикасы Чүпрәле районы) мулла гаиләсендә туа. 1830 елларда бабасы Югары Каракитә авылыннан килеп Түбән Чәке мәхәлләсендә мулла вазыйфасын башкара. 1851 елны (тугызынчы ревизиядә) гаиләсе белән рәсми рәвештә Түбән Чәке авылында теркәлә[17]. Нәни Һади әтисеннән алган башлангыч белемне Буа мәдрәсәсендә дәвам итә. Аннан Оренбург якларына китеп, Каргалы бистәсендә Фатих Кәрими җитәкләгән (Ғани бай Хөсәеневнең матди ярдәме белән оештырылган) җәйге укытучылар семинариясендә белем өсти, 1898-1901 елларда үзе укыган Буа мәдрәсәсендә

* Автор Һади Атласының оныгы Әлфия Угыс кызына истәлекләр белән бүлешкәне өчен рәхмәтен белдерә.

укыта, фәнни эшчәнлеге дә шунда башлана. Яңа дәреслекләр төзи, астрономия һәм табигать фәне буенча китаплар бастырып чыгара.

1903 елдан Самара губернасы Иске Әлмәт авылына (хәзерге Татарстан Республикасы Әлмәт шәһәре) мулла булып билгеләнә. 1903-1909 елларда указлы мулла вазыйфасын башкара, балалар укыта. 1903 елның 6 июнендә Түбән Чыршылы авылы муллысы Габделфәттах кызы Хөсникамал белән никахлаша. Яшь парның тормышка карашы уртак була, бергәләшеп кызлар мәктәбе ачалар[18].

1907 елны Һ. Атласи Самара губернасыннан II Дәүләт Думасына депутат итеп сайлана. Ул «Мөселман хезмәт тайфасы» («Мөселман хезмәт группасы») составына керә. Аның фикердәшләре: Бакудан – З. Зейналов, Уфа губернасыннан – К. Хәсәнов, Сембер губернасыннан – Нәҗметдинов, Казан губернасыннан – Г. Бадамшин, Вятка (Нократ) губернасыннан – Мәсхутов[19]. Җаваплы редактор К. Хәсәнов белән берлектә «Дума» газетасы чыгаралар.

Һ. Атласиның 1906 елда «Яңа низам вә голямаларымыз» («Яңа закон һәм укымышчыларыбыз») дигән брошюрасы басылып чыга. 1908 елда бу хезмәт буенча тикшерү процессы башланып 1909 елда тәмамлана. Һ. Атласи суд карары белән килешми, бәхәскә керә, әмма барыбер 1910 елда өч ай төрмәдә утырып чыга. Муллалык указын алалар.

1909 елдан 1917 елгы кискен борылышка кадәр фәнни эш белән шөгыльләнә, тик һәрвакыт полиция күзәтүе астында була. Бу елларда «Себер тарихы», «Сөенбикә», «Казан ханлыгы» хезмәтләрен яза. «Шура» журналы, «Вакыт» һәм «Йолдыз» газеталарында мәкаләләр бастыра.

1917 елда илдә кискен үзгәрешләр башлана. 1919 елның язына кадәр (Колчак һөҗүм итә башлаганчы) Һ. Атласи укытучы булып эшли. Земство идарәсе рәисе урынбасары була, Уфаның Милли мәҗлес оешмасы эшләрендә катнаша. Соңыннан Колчак гаскәрләренә ияреп Бөгелмәдән китә, Чиләбегә җиткәч, Германиягә китәргә уйлый. Троицк, Орск, Актүбә, Тимур, Гурьев шәһәрләре аша Иранга чыга[20]. Аннан элеккеге танышлары янына Бакуга кайта һәм Кубан урамында 13 йортта урнашкан «Эшчеләр клубының» аскы катында яши. Халык мәгарифе комиссариатының төрек нәшрияты бүлегендә эшли.

1920 елның 1 сентябрендә Бакуда совет власте урнашкач, Һ. Атласины Гадәттән тыш диңгез транспорт комиссиясе кулга ала. Колчакчыларга хезмәттәшлек күрсәтүдә гаепләнә. Тикшерү эше Бөгелмәгә җибәрелә. 1922 елның 1 апрелендә Чистай районы революция трибуналы суды Һ. Атласины азат итә[21].

1920 елда Һ. Атласи кулга алынгач, 2 сентябрендә сорау алу вакытында язылган анкетасы сакланган. Анкетадан 78 яшьлек әнисе Сәрвиҗамал апаның (1842) улы Һади тәрбиясендә яшәгәнлеге аңлашыла. Гаиләсе турында әлеге мәгълүматлар теркәлгән: хатыны Хөсникамалга 35 яшь (1885), балалары Сәлма – 12 яшь (1907), Габделбәр – 8 яшь (1911), Илтөзәр – 2 яшь (1918)[22], Сылу (1922), Көн (1925), Угыз (1927) һәм игезәк Илсөя (1929) һәм Илсөяр (1929-1930). Моннан тыш, А. Р. Вәлиев белән Ә. Ф. Ялалова төзегән шәҗәрәдә Сәгъдә (1909-1910), Сәгъдә (1913-1917) исемле кызлары булганлыгы күрсәтелгән[23].

1922 елдан Һ. Атласи Бөгелмәнең икенче баскыч мәктәбендә тарих, география фәннәрен һәм алман телен укыта. Ул абыйлы-энеле Туйкиннар белән бер коллективта эшли. Әйтеп үтик, Татарстан Республикасының атказанган



Бөгелмәдә Һ. Атласи гаиләсе яшәгән йорт. 1970 нче еллар башы // Татарстан Республикасы Дәүләт архивы, Р6800 ф., 1 тасв., 15 сакл. бер., 1 кгз.

The house where the family of Kh. Atlasi lived. Early 1970s. // State Archive of the Republic of Tatarstan, fund R6800, series 1, file 15, p. 1.

укытучылары Ә. Каюмова, Г. Мостафина-Рәфыйкова, В. Хаҗиев, Х. Кәримов – аның укучылары.

1929 елны Һади Мифтахетдин улы яңадан кулга алына һәм «солтангалиевчелектә» гаепләнеп 10 елга хөкем ителә. Барлык мал-мөлкәтләре тартып алына, тарихчы-галимнең китапханәсе юкка чыгарыла. Гаилә тормышы коточкыч авырая, Көн, Илсөя һәм Илсөяр ачлыктан вафат була (Илтөзәр үлгән була инде). Шулай итеп, бары тик Сәлма, Габделбәр, Сылу һәм Угыз әниләренә терәк булып үсәләр.

Ниһаять, 1933 елда Һади Атласины азат итәләр. Сәбәбен «сәламәтлеге какшау» дип күрсәтсәләр дә, элекке танышлары Вәлиев Гашим һәм Балтанов Гариф ярдәм иткәнлеге ачыкланды[24]. Шулай ук бу елны өлкән яшьтәге тоткынларны туганнары килеп алса, җибәрергә ярый дигән карар да чыккан була. Хөсникамал абыстай Соловкига барып ирен Бөгелмәгә алып кайта. Эшкә урнашу белән тагын кыенлыклар килеп чыга. Яшәгән шәһәрендә эш таба алмагач, Уфага Риза Фәхретдин янына да барып карый. Чарасызлыктан, 1934 елда гаиләсен алып, Казанга күчә һәм Яңа Бистәнең Эш урамының 32 йортында фатир яллап яши. Ниһаять, Казан шәһәре Сталин районының 12 нче мәктәбенә алман теле укытучысы булып урнашырга педагог дуслары – Рәхмәтуллин Мәхмүт, Богданов Гариф ярдәм итә[25]. Тик, Атласиның тормышы һаман җайланмый, күзәтүләр дәвам итә.

Бу елларда мәктәптә марксизм-ленинизм түгәрәге эшли. Һади Атласов 10-20 октябрьдә уздырылган политукуда катнашудан баш тарта. 9-10 кеше җыелган класстан «Мин сәясәт белән шөгыльләнгән кеше, марксизм-ленинизмны өйрәнү белән борчымагыз. Биш ел төрмәдә утырганым өчен генә өйрәнергә теләмим, яңадан төрмәгә утырасым килми», – дип чыгып китә[26]. Аны укуны өзүдә гаеплиләр.



Х. Атласованың ире Һ. Атласи белән күрешүне сорап язган гаризасы // Татарстан Республикасы Дәүләт архивы, Р6800 ф., 1 тасв., 16 сакл. бер., 1 кгз.

Statement by Kh. Atlasova requesting a meeting with her husband Kh. Atlasi. // State Archive of the Republic of Tatarstan, fund R6800, series 1, file 16, p. 1.

1935 елның мартында ул тагын эшсез кала һәм 1936 елның 27 июлендә яңадан кулга алына. Хөсникамал апаның НКВД органнарына ире белән күрешүне һәм тикшерүче Мозафаров исеменә киемсалым тапшырырга рөхсәт сорап язган ике гаризасы фондта саклана[27].

Галим контрреволюцион эш алып баруда, чит илләрдәге ак эмигрантлар белән бәйләнештә һәм совет хөкүмәтенә каршы эш йөртүдә гаепләнә. Шул ук вакытта Бөгелмәдәге хезмәттәшләре, руханилар да кулга алына. «Атласовщина» дигән тикшерү эше барлыкка килә. 1936-1937 елларда-гы сорау алу материаллары арасында күренекле галимнәр, язучыларның да исемнәре бар: Ш. З. Мөхәммәдьяров, Г. Шәрәф, Ф. Сәйфи-Казанлы, Һ. Максуди һ. б.[28]

1937 елның 28 октябрендә хөкем карары игълан ителә. 1938 елның 15 февраленда суд карары тормышка ашырыла. 1958 елның май аенда СССР Югары суды Хәрби коллегиясе Һ. М. Атласовны реабилитацияли[29].

Әлбәттә, Һади Атласи турында тиешле органнарга җиткереп торучылар да була. Шуларның берсе аның кияве – Җиһанша Дунаев. Һ. Атласиның сорау алу эшен өйрәнгән тарихчы А. Л. Литвин әлеге мәсьәлә буенча болай яза: «1937 елның 23 гыйнварында сорау алу вакытында Атласов үзенең “контрреволюцион милләтчел оешманың” оештыручысы һәм җитәкчесе булуын таныргa мәҗбүр була. Ул мондый оешманың беркайчан да булмаганын тулысынча аңласа да, бөтен җаваплылыкны үз өстенә ала. Ләкин НКВД хезмәткәрләренә бу гына җитми... Сорау барышында Атласов шпионнар белән бәйләнешен катгый рәвештә кире кага. Ләкин тикшерүчеләр моның белән туктамый, төрле ялган гаепләр өстәлә. Якын туганнары – кызының ире (Ж. Дунаев), хатынының абыйсы һәм башка якын кешеләре төрле җәфалауларга дучар ителә. Тикшерүчеләр тәкъдим иткән кәгазьләргә кул куярга ризалашканчы аларның нинди газаплар кичергәннәрен аңлату кыен. Атласовның якыннары аны буржуаз-милләтче, “контрреволюцион оешманың” лидеры булуын әйтәләр. Хәер, моны Һади Атласи үзе дә таныган була. Ләкин аларның берсе дә аның “чит ил белән бәйләнешләрен” расламый»[30].

Димәк, Ж. Дунаев НКВД тикшерүчеләренең басымы астында Һ. Атласины кайбер мәсьәләләрдә гаепләргә мәҗбүр була. Чөнки гаиләсе, балалары, туганнарының язмышын кайгырту мәсьәләсе алгы планга чыга*.

1957-1958 елларда өстәмә тикшерү вакытында Ж. Б. Дунаев, Г. М. Әхмәров, А. М. Гобәйдуллиннарны яңадан органнарга чакырталар. Җинаять эшен туктатырга дигән карар кабул ителә[31].

Нәсел варислары

Һ. Атласиның дүрт баласы исән кала. Өлкән кызы Сәлма 1907 елның 26 июлендә Иске Әлмәт авылында дөньяга килә. Беренче мәхәлләнең метрика кенәгәсендә әтисе указной имам Һади Мифтахетдин улы, әнисе Хөсникамал Габделфәттах кызы дип язылган[32]. Бөгелмәгә күчкәндә Сәлмагә 10 яшь була. 1925 елны әтисе кызын Казанга алып килә һәм ул университетка укырга керә. Тик уку йортын уңышлы тәмамлап аспирантурада калырга теләгән «халык дошманы» кызына урын табылмый. 1930 елда Симферополь университетына аспирантурага урнаша, ике айдан соң анда да укуын ташларга мәҗбүр була. Университет ашханәсендә, әтисенең укучыларын очратып сөйләшкәннән соң, икенче көнне үк ректор Сәлмане чакыртып, кулына приказ тоттыра. Стипендиясен дә бирмичә аны укудан чыгаралар. Кыз Мәскәүдән Ерак Көнчыгышка юллама алырга мәҗбүр була.

1934 елны Казанга ялга кайткач, Сәлма Атласова Казан медицина институтын тәмамлаган табиб Ж. Дунаевка кияүгә чыга[33]. 1936 елның сентябреннән Казан шәһәрендәге Татар халык мәгарифе кадрларының квалификациясен күтәрү институтында физика-математика бүлеген җитәкли, математика укыта. Әтисе «солтангалиевчелектә» гаепләнгәч, 1937 елның 22 мартында Мәгариф халык комиссары Ш. Г. Башкиров боерыгы буенча эшеннән азат ителә[34].

Җиһанша 1899 елның 12 мартында Баһаветдин Зәйнетдин улы гаиләсендә Татар Бизнәсе авылында туа. Әнисе – Хәдичә Камалетдин кызы[35].

1934-1936 елларда Ж. Дунаев «Каменка» туберкулез санаториясенең баш табибы булып эшли[36]. Бөек Ватан сугышы башлангач, Казанда формалашкан ОРМУ-35 составында хәрби табиб булып фронтка китә. 1941-1942 елларда Көнбатыш фронтта, 1942-1943 елларда Дон фронтының 3 812 номерлы кыр госпиталенең җитәкче урынбасары булып хезмәт итә[37]. 1943 елның 24 февралендә контузия ала һәм Казан шәһәрендәге медицина институты торагында урнашкан 1 673 һәм ветеринария техникумы бинасындагы 5 865 номерлы госпитальдә хәрби табиб булып хезмәт күрсәтә[38].

Сәлма сугыш елларында Татар Бизнәсе авылына кайтып яши. Уллары Рөстәм вафат була, Фәридә һәм Энҗе исемле кызлары, соңрак Рауза туа. Җиһанша гаиләсенә фронттан акчалата ярдәм итеп тора: «Кадерле туганнарым! Мин бик шатмын 700 сум акчаны алганыгызга, кызганыч соңга калып килгән. Әле октябрь аенда 700 сум җибәргән идем, 7 ноябрьгә кадәр килеп җитәр дип уйлыйм. Мин һичшиксез Фәридә һәм Энҗегә бүләкләр алып кайтырмын, нәрсә алыйм, языгыз...» (5.10.42)[39].

Ж. Дунаев Казан Суворов хәрби училищесы лазаретында табиб булып эшләгән вакытта, 1947 елның 23 гыйнварында Кызыл Йолдыз ордены белән

---

* Һ. Атласиның туганнары Ж. Дунаевның тикшерү органнарына язган шикаяте турында белмәгәннәр дип уйларга да җирлек бар. Угыз Атласов XX йөзнең 90 елларында гына архивлардан суд эшләре белән таныша һәм аның бу вакыйгаларга үзенең карашы була.

бүләкләнә. Аның белән бергә бу елларда Сәлманең сеңлесе Сылу да шәфкать туташы булып эшли. 1950 елларда Казан шәһәренең өченче номерлы хастаханәсен җитәкли[40]. 1965 елның 13 июнендә Ж. Дунаев вафат була һәм Яңа Бистәдәге татар зиратына җирләнә.

Сәлма ханым укытучы булып эшли. Балалары белән Таллин шәһәрендә яши. 94 яшендә бакыйлыкка күчә. Ире Җиһанша һәм кызы Рауза янында җирләнгән.

Һади Атласиның икенче улы Габделбәр 1911 елның 3 мартында Әлмәттә туа[41]. Бөгелмәдә яшәгәндә урманчылыкта эшли. Әтисе киңәше белән алман телен өйрәнә. 1931 елны иптәшләре белән Русия чиген чыкканда кулга алына һәм Совет властена каршы пропаганда алып баруда гаепләнә. 9 майда дәлилләр җитмәү сәбәпле азат ителә[42]. Энесе – Угыз Атласов Мәскәүнең Бутырка төрмәсендә Габделбәрнең әтисе белән очрашулары турында истәлекләрендә яза[43].

Габделбәр 1935 елның 1 сентябрендә Мәскәү шәһәренең Менделеев исемендәге химия-технология институтында укый башлый. Беренче курсны яхшы билгеләренә генә тәмамлый. Зачет кенәгәсеннән икенче курсның беренче семестрында барлыгы өч имтихан гына тапшырылганы гына күренә[44]. Бу хәл 1937 елның гыйнвар аенда була. Әтисенең кулга алынуы турындагы хәбәр институтка килеп җиткән була күрәсең.

Сугыш башлангач лейтенант Г. Г. Атласовны Баку шәһәренең Говсан поселыгында урнашкан электромеханика институтына җибәрәләр[45]. Институт СССРда Хәрби-диңгез һәм Гражданнар флоты өчен штурм җиһазлары һәм приборлар, навигация комплексларын уйлап табу белән шөгыльләнә. 1944 елда хәрби хезмәтен Суслонгерда дәвам итә.

Сугыш беткәч, 1946 елның гыйнварыннан Мәскәүдә яши. Паспорт ала, яшәү урынына теркәлә. Фәнни эшкә урнашканчы тукымалар буяу белән дә шөгыльләнә. «Проектпромвентиляция» институтында инженер-химик булып эшли.

Габделбәрнең Сәлмага язган хатында кандидатлык диссертациясе өстендә эшләве турында түбәндәге юллар бар: «...Соңга калып булса да, кандидатлык диссертациясен яклауның катлаулы процедурасын башларга уйлыйм. Алман теле буенча имтихан тапшырудан башладым, көзен фәлсәфә, ә 1954 елда – махсус фәннәр тапшырырмын. Диссертация өчен материал җитә дип уйлыйм...» (22.06.53)[46].

Габделбәр Һадиевич кулланма (коллектив хезмәт) һәм фәнни мәкаләләр авторы[47], патентлары[48] да бар. Шулай булса да ниндидер сәбәпләр аркасында кандидатлык диссертациясен якламаган. Сәламәтлеге дә начарланып киткән, операция дә кичергән.

Хатыны Лиля белән алар институтта танышалар. 1949 елны аларның Галия исемле кызлары туа. Бу елларда Хөсникамал апа Габделбәр белән Сәлма гаиләләрендә яши.

1981 елда Габделбәрнең Угызга язган хаты аеруча игътибарга лаек: «Кадерле Угыз! Муфузагә, Әлфиягә һәм мин белмәгән Һадига күп сәлам. Мин Казанга килеп, әнинең каберстаннарын йөреп, җирләрен чистарттым. Әмма Рауза каберенә ташын эшләтергә сораган идем, Мәскәүдән әни ташын эшләгән татар егете хәзер эшләми икән, шул сәбәпле, анда минем танышлар калмады...»[49].

Казанның 1981 еллардагы тормышын Габделбәр хатында түбәндәгечә тасвирлый: «...Бу юлы Казан уңайлырак тәэсир калдырды: ...татар теле көчлерәк һәм

ешрак яңгырый. Шәһәр сизелерлек чиста булып күренә, һәр чәршәмбе “Чисталык көне” дип игълан ителгән. Завод, фабрика һәм башка оешмалардан эшчеләр җыештыра...» (31/VII-81)[50].

Өч тапкыр Казан университетның фәнни китапханәсендә әтисенең хезмәтләре белән танышырга тырышса да барып чыкмый. Беренче тапкыр килгәндә гарәп хәрефендәге татар китаплары фондында электр яктылыгы булмый. Ике ел элек кайтканда китапханә яңа бүлмәгә күчкән вакыт була. Соңгы кайтуында китап фондлары чираттагы күчүе сәбәпле, ул тагын бернәрсәгә дә ирешә алмый.

1994 елда Габделбәр Һади улы вафат була.

Һ. Атласиның икенче кызы Сылу 1922 елда Бөгелмәдә туа. Казанга күчкәч, 1935-1940 елларда Сталин районының икенче мәктәбендә яхшы билгеләренә генә укып, 10 классны тәмамлый[51]. Медицина институтында укыганда ук Суворов училищесы лазаретында шәфкать туташы булып эшли. 1948 елны институтны тәмамлап ординатурада кала. Ләкин ординатураны тәмамлый алмый, Казаннан китәргә мәҗбүр була.

Сылуның шәхси тормышына килгәндә, ул Казанда яшәгәндә Сәлма апаларының күршесенә кияүгә чыккан була. Апасына язган хатта: «...күршегезгә әйтегез әле, аерылышуны рәсмиләштерсен...», – дигән юллар бар (24.05.53)[52]. 1962 елны Калининградта үзеннән 10 яшькә өлкән, яр буенда хезмәт итүче диңгез флотының элеккеге офицерына кияүгә чыга һәм соңарып кына Фәридә исемле кыз бала таба[53].



ОЦЕНКА УСПЕВАЕМОСТИ, ПОСЕЩАЕМОСТИ И ХАРАКТЕРИСТИКА УЧАЩЕГОСЯ

Наименование предметов / Четверти

Русский, Татарский, Литература, Немецкий, История, Обществовед., География, Арифметика, Алгебра, Геометрия, Тригонометр., Физика, Химия, Биология, Черчение, Рисование, Пение, Технология, Труд (дерево), Труд (металл), Физкультура, Военное дело

Заключение о переводе в след. класс, даче поверочных испытаний на осень, об оставлении на 2-й год или выпуске из школы.

I четверть. . .
II четверть. . .
III четверть. . .
IV четверть. . .
Годовая отметка .
Испытания . . .
Переводная (общая)

Переходится в VII кл.

Четверти	Пропуски занятий: Пропущено полных дней	В том числе по болезни	Пропущено уроков	Было всего опозданий
I	[illegible]	*1	5	1
II	—	—	—	—
III	—	—	—	—
IV	—	—	—	—

Четверти	Характеристика общественной работы	Дисциплина	Подпись классовода	Подпись родит. или заменяющих их лиц
I	Отлично	Отлично	Выборн	Атласова
II	отл.	отл	Выбор	Атласова
III	отлично.	отлично	Выборн	Атласова
IV	отлично	отлично	Выборн	Атласова

VI «е» сыйныф укучысы Атласова Сылуның 1935/1936 уку елы өчен билгеләре // Татарстан Республикасы Дәүләт архивы, Р6800 ф., 1 тасв., 20 эш, 2 кгз.

Report card of student Atlasova Sylyu, class VI “E”, for the 1935/1936 academic year // State Archive of the Republic of Tatarstan, fund R6800, series 1, file 20, p. 2.



Сылу Атласованың әнисенә, Сәлма апасына һәм Угыз энесенә язган хатлары. Татарстан Республикасы Дәүләт архивы, Р6800, 1 тасв., 25 эш, 31, 60, 69 кгз.

Letters of Sylyu Atlasova to her mother, sister Salme, and brother Ugyz. State Archive of the Republic of Tatarstan, fund R6800, series 1, file 25, p. 31, 60, 69.

Сылу Советлар Союзының төрле җирләрендә табиб булып эшли. 1949-1956 елларда Фирганә өлкәсендә Язъявам, Маргилан больницаларында терапевт булып хезмәт итә. 1957 елдан Себергә күчә. Хатларының берсендә «...Ун койкалы авыл хастаханәсенә җибәрделәр. Авыл зур, урман янында урнашкан, кечкенә генә елга ага. Бүген иртә белән күзләремә ышанмадым: тирә-якта ак кар яуган һәм хәзер дә дәвам итә, көчле җил. Себер безнең яклардан аерылып тора. Кибетләрендә бернәрсә юк. Хуҗабикә яхшы, бик чиста...», – дип яза (19.05.57)[54]. 1958 елда Ленинградта эшләп ала һәм 1959 елдан Калининградта урнаша. Әнисен үз янына яшәргә чакыра: «...Әни, минем янга килсәң яхшырак булыр, диңгез һавасында гипертония белән авыручылар үзләрен яхшырак хис итә һәм кан басымы кими. Бигрәк тә хәзер минем ике бүлмә булды. Синең үз бүлмәң булачак. Мин ремонт ясадым, бүлмә бик уңайлы, җылы һәм коры...» (18.01.62)[55]. 1965 елдан Хөсникамал абыстай соңгы көненә кадәр кызы Сылу тәрбиясендә яши. Аның җәсәтен Калининградтан Казанга самолет белән кайтарталар. 1968 елның 4 январендә әниләрен соңгы юлга озаталар. Казандагы Татар бистәсе зиратына җирлиләр.

Ирен һәм кызын югалткач, Сылу Калининградтан Казанга күчә һәм 2000 елда вафат була.

Һади Атласиның төпчек улы Угыз 1927 елны Бөгелмәдә туа.

«Әтием тәрбиясен алмасам да (балачак елларымда ул төрмәләрдән чыкмады, гомере дә төрмәдә үзелде), әнием мине әтием рухында тәрбияләде», – дип искә ала ул[56].

Угыз балачактан шаян, шук булып үсә. Һ. Атласи хатыны Хөсникамалга язган хатында: «Угызның шаян булуына кәеф китәргә ярамый, шатланырга кирәк. Шаян, уйнак, шат бала таза, күтәренке рухлы, батыр була. Бу мәсьәләне мин элек тә сөйли идем бугай. Тагы да бер кат әйтәм: балаларның саулыкларына һәм матди вә мәгънәви тәрбияләренә артык әһәмият биреп, төп мәсьәләң шул булсын!» (8.11.1930)[57].

1935 елны Угыз татар классына мәктәпкә укырга керә. Хәрби хезмәттән соң, Екатеринбург шәһәрендә югары белем алып, инженер-электрик булып эшли. Аны Сәлманең кызлары кирәкле китаплар белән тәэмин итеп торалар.

1968 елда Угыз Казанга әнисен соңгы юлга озатырга кайта. Әнисе вафатыннан соң күп тә узмый, Угыз гаилә корып җибәрә. Бөгелмәдә хатыны Муфуазә, кызы Әлфия һәм улы Һади белән яши.

Угыз Атласов үзгәртеп кору елларында әтисенең исемен аклауга күп тырышлык куя. «Город счастливой судьбы» (Казань, 1981) китабы басылып чыгу бу мәсьәләне яңадан күтәреп чыгарга этәрә. Әтисен югалтканда 10 яшендә булган бала бу вакыйгаларның барлык нечкәлекләрен хәтерләп тә бетерми. Ул Сәлма апасына хат язып сораша. Бу вакыйгаларга 45 ел узса да, Сәлма хатында сакчыллык күрсәтә, «теге елларның» шомлы кайтавазы аны һаман озата килә...

Угыз Атласов 2003 елда вафат була.

Бөгелмә шәһәрендә Һ. Атласи укыткан мәктәп бинасында Һади Атласи һәм аның фикердәшләре исемнәре язылган мемориал такта куелган. Улы Угыз Атласов һәм татар җәмәгатьчелеге тырышлыгы белән төзелгән «Һади Атласи» фонды эшли. Быел аның туган авылы Түбән Чәке мәктәбенә Һади Атласи исеме бирелде.

Яңа Бистә татар зиратында бер чардуган эчендә Хөсникамал абыстай янына балалары – Габделбәр, Сылу һәм Угыз күмелгән. Һади Атласиның исеме дә бу каберлектә мәңгеләштерелгән.

Совет власте елларында Һади Атласиның балаларын чикләүләргә карамастан, алар тормышта үз юлларын тапкан. Барысы да югары белем алып, һөнәрләрен яратып халкыбызга хезмәт иткәннәр.



Һади һәм Хөсникамал Атласовларга Казанда Татар зиратында куелган кабер ташы. Авторның шәхси архивыннан.

Gravestone of Khadi and Khusnikamalu Atlasov at the Tatar cemetery in Kazan. Rom the author's personal archive.

ИСКӘРМӘЛӘР:

1. *Абдуллин Я. Г., Госманов М. Г., Таһиров И. Р.* Һади Атласи – галим һәм җәмәгать эшлеклесе // Казан утлары. – 1986. – № 11. – Б. 172-176.
2. *Госманов М. Г.* Авыр тарихның моңлы кайтавазы // Атласов Һ. Сөен-бикә. – Казан: "Җыен" фонды, 1992. – Б. 64-71; Үткәннән – киләчәккә. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1990. – Б. 71-79.
3. *Султанбеков Б. Ф.* "Дело" Хади Атласова: в контексте политической атмосферы 30-х годов // Первая жертва Генсека. Мирсаид Султан-Галиев: Судьба. Люди. Время. – Казань: Татар. кн. изд-во, 1991. – С. 72-99.
4. *Алишев С. Х.* Тарихчының фажигале язмышы // Социалистик Татарстан. – 1990. – 5 август; Татар тарихчысы Һади Атласи // Себер тарихы; Сөен-бикә; Казан ханлыгы: Тарихи әсәрләр. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1992. – Б. 3-15.
5. *Кәримуллин Ә. Г.* Һади Атласи һәм аның «Сөен-бикә»се // Язмыш, язмыш. – Казан, 1996. – Б. 126-128.
6. *Литвин А.* Милләтчеләр эше: Һ. Атласов турында архивлар ни сөйли? // Казан утлары. – 1993. – № 4. – Б. 155-166; Операция "националисты"// Запрет на жизнь. – Казань: Татар. кн. изд-во, 1993. – С. 42-60.
7. *Усманова Д.* Мусульманская фракция и проблемы «свободы совести» в Государственной Думе России (1906-1917). – Казань: Мастер-Лайн, 1999. – С. 56, 67, 129, 141.
8. *Хаҗиев В.* Педагог һәм тарихчы Һади Атласов // Мәгариф. – 1991. – № 10. – Б. 55-57; Һади Атласи мәктәбе // Мирас. – 1995. – №7/8. – Б. 108-113.
9. *Каюмова Ә.* Үткән юллар, үткән еллар... // Мирас. – 2000. – № 6. – Б. 73-74.
10. *Асылов Д.* Мәйдан тотучыларның берсе // Татарстан. – 1997. – № 1. – Б. 66-73.
11. *Атласов У.* Ачы хакыйкать: Һ. Атласиның тууына 115 ел тулу уңаеннан // Бөгелмә авазы. – 1991. – 27 август.
12. *Мухаметдинова А. Х.* Хади Атласи как историк: дис. ... канд ист. наук. – Казань, 2003.
13. Һади Атласи: Тарихи документаль җыентык / Төз.-авт. *Р. Миңнуллин, А. Мөхәмәтдинова, И. Һадиев.* – Казан: Җыен, 2007. – 400 б.
14. *Галлям Р. Г.* Хади Атласи: новые сведения по биографии и родословной // Из истории и культуры народов Среднего Поволжья: Сб. статей. Вып. 3. – Казань: Изд-во «Ихлас»; Институт истории им. Ш. Марджани АН РТ, 2013. – С. 55-63; *Гафаров И.* Һади Атласи турында яңа чыганаклар // Казан утлары. – 2016. – № 8. – Б. 6-12.
15. Татарстан Республикасы Дәүләт архивы, Р-6800 ф., 1 тасв., 27 эш.
16. Шунда ук, Р-779 ф., 3 тасв., 33 эш.
17. Ульяновск өлкәсе Дәүләт архивы, 156 ф., *2 тасв.*, 602 эш, 90 *арткы ягы* – 91 кгз.
18. *Мөхәмәтдинова А.* Һади Атласиның тормыш юлы һәм эшчәнлеге // Һади Атласи: Тарихи документаль җыентык / Төз.-авт. *Р. Миңнуллин, А. Мөхәмәтдинова, И. Һадиев.* – Казан: Җыен, 2007. – Б. 17.
19. Татарстан Республикасы Дәүләт архивы, Р-779 ф., 3 тасв., 33 эш, 80 кгз.
20. Шунда ук, 81 кгз.
21. Шунда ук, 144 кгз.
22. Шунда ук, 78 кгз.
23. *Вәлиев А. Р., Ялалова Ә. Ф.* Шәҗәрә // Кулъязма.
24. Татарстан Республикасы Дәүләт архивы, Р-3682, ф. 1л. тасв., 117а эш, 14 кгз. арткы ягы.
25. Шунда ук.
26. Шунда ук, 137 кгз.
27. *Мөхәммәтдинова А.* Күрс. хез. – Б. 44.
28. Атласов Мухаммед-Хади Мифтахутдинович. URL: https://bessmertnybarak.ru/Atlasov_Mukhammed_Khadi_Miftakhutdinovich/ (мөрәҗәгать итү датасы: 15.05.2026)
29. *Мөхәммәтдинова А.* Күрс. хез. – Б. 43.
30. *Литвин А. Л.* Операция «националисты» // Запрет на жизнь. – Казань: Татар. кн. изд-во, 1993. – С. 49.

31. Обзорная справка // Һади Атласи: Тарихи документаль җыентык / Төз.-авт. *Р. Миңнуллин, А. Мөхәмәтдинова, И. Һадиев.* – Казан: Җыен, 2007. – Б. 244-247.
32. Татарстан Республикасы Дәүләт архивы, 204 ф., 177 тасв., 1019 эш, 107 кгз.
33. Шунда ук, Р-6800 ф., 1 тасв., 25 эш, 83 кгз.
34. Шунда ук, Р-3682 ф., 39 тасв., 14 эш, 59 кгз.
35. Шунда ук, 204 ф., 10 өстәмә. тасв., 9 эш, 2 кгз.
36. Шунда ук, Р-2852 ф., 1л. тасв., 2 эш, 5 арткы ягы, 88 кгз.
37. *Салахиев Р. Р.* Краткие биографические справки о казанских врачах – начальниках эвакогоспиталей в Татарстане // История России и Татарстана: итоги и перспективы энциклопедических исследований. Сборник статей итоговой научной конференции научных сотрудников Института Татарской энциклопедии и регионоведения АН РТ. Вып. 14. – Казань, 2022. – С. 166.
38. *Салахиев Р. Р.* Эвакогоспитали Татарстана в 1941-1945 годы: дислокация, специализация, начальники // Сборник документов о работе эвакогоспиталей Татарской АССР в 1941-1945 годы. – Казань: Отчество, 2020. – С. 79, 89.
39. Татарстан Республикасы Дәүләт архивы, Р-6800 ф., 1 тасв., 23 эш, 84 кгз.
40. Шунда ук, Р-535 ф., 1 тасв., 154 эш, 10 кгз.
41. Шунда ук, 204 ф., 177 тасв., 11155 эш, 359 арткы ягы кгз.
42. Атласов Габдулбар Гадиевич (1911). URL: https://clck.su/dEuaT (мөрәҗәгать итү датасы: 07.07.26).
43. *Атласов У.* Әтием турында хатирәләр // Һади Атласи: Тарихи документаль җыентык / Төз.-авт. Р. Миңнуллин, А. Мөхәмәтдинова, И. Һадиев. – Казан: Җыен, 2007. – Б. 63.
44. Татарстан Республикасы Дәүләт архивы, Р-6800 ф., 1 тасв., 21 эш, 1-4 кгз.
45. Шунда ук, 23 эш, 5 кгз.
46. Шунда ук, 23 эш, 46 кгз.
47. Наладка и регулирование систем вентиляции и кондиционирования воздуха. Справочное пособие / *Б. А. Журавлев, Г. Я. Загальский, Р. Н. Гобза, П. А. Овчинников, Н. М. Сорокин, А. Г. Атласов, В. Я. Меклер.* – М.: Стройиздат, 1980. – 447 с.; *Муравьева С. И., Бабина М. Д., Атласов А. Г., Новикова И. С.* Санитарно-химический контроль воздуха промышленных предприятий. – М.: Медицина, 1982. – 352 с.; Атласов А. Г. Классификация вредных веществ по их агрегатным состояниям в воздушной среде производственных помещений. URL: https://clck.su/qLmeB (мөрәҗәгать итү датасы: 07.07.2026); *Атласов А. Г.* Надо ли приводить объем аспирируемого воздуха к нормальным условиям при санитарном контроле воздушной среды? URL: https://clck.su/uYfPG (мөрәҗәгать итү датасы: 07.07.2026); *Атласов А. Г., Минюшина М. С., Котова В. Г.* Определение аэрозоля едких щелочей колориметрическим способом. URL: https://clck.su/iaWOS (мөрәҗәгать итү датасы: 07.07.2026); *Атласов А. Г.* О летучести дибутилфталата и возможных концентрациях его воздухе помещений. URL: https://clck.su/pxzQR (мөрәҗәгать итү датасы: 07.07.2026).
48. *Атласов А. Г., Новиков А. Г.* Способ определения количества двуокиси хлора в воздухе. Описание изобретения к авторскому свидетельству 314132. Опубликовано 7.IX.1971. Бюллетень № 27. URL: https://patentdb.ru/image/634414 (мөрәҗәгать итү датасы: 07.07.2026).
49. Татарстан Республикасы Дәүләт архивы, Р-6800 ф., 1 тасв., 25 эш, 82 кгз.
50. Шунда ук,. 80 кгз.
51. Шунда ук, 20 эш, 1-2 кгз.
52. Татарстан Республикасы Дәүләт архивы, Р-6800 ф., 1 тасв., 25 эш, 50 кгз.
53. Шунда ук, 66 кгз.
54. Шунда ук, 46 кгз.
55. Шунда ук, 61 кгз.
56. *Атласов У.* Күрс. хез. – Б. 60.
57. Һ. Атласиның гаиләсенә язган хаты // Һади Атласи: Тарихи документаль җыентык / Төз.-авт. *Р. Миңнуллин, А. Мөхәмәтдинова, И. Һадиев.* – Казан: Җыен, 2007. – Б. 164.

Әдәбият исемлеге

Галлям Р. Г. Хади Атласи: новые сведения по биографии и родословной // Из истории и культуры народов Среднего Поволжья: Сб. статей. Вып. 3. – Казань: Изд-во «Ихлас»; Институт истории им. Ш. Марджани АН РТ, 2013. – С. 55-63.

Литвин А. Л. Операция "националисты"// Запрет на жизнь. – Казань: Татар. кн. изд-во, 1993. – С. 42-60.

Мухаметдинова А. Х. Хади Атласи как историк: дис. ... канд ист. наук. – Казань, 2003. – 149 с.

Себер тарихы; Сөен-бикә; Казан ханлыгы: Тарихи әсәрләр. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1992. – 448 б.

Султанбеков Б. Ф. "Дело" Хади Атласова: в контексте политической атмосферы 30-х годов // Первая жертва Генсека. Мирсаид Султан-Галиев: Судьба. Люди. Время. – Казань: Татар. кн. изд-во, 1991. – С. 72-99.

Һади Атласи: Тарихи документаль җыентык / Төз.-авт. *Р. Миңнуллин, А. Мөхәмәтдинова, И. Һадиев.* – Казан: Җыен, 2007. – 400 б.

References

R. G. Galliam. *Hadi Atlasi: novye svedeniya po biografii i rodoslovnoj* [Khadi Atlasi: New Information on Biography and Genealogy]. IN: *Iz istorii i kul'tury narodov Srednego Povolzh'ya: Sb. statej* [From the history and culture of the peoples of the Middle Volga region: Collection of articles]. Issue 3. Kazan: Ikhlas Publishing House; Sh. Marjani Institute of History, Academy of Sciences of the Republic of Tatarstan, 2013, pp. 55-63.

Litvin A. L. *Operaciya "nacionalisty"* [Operation "Nationalists"]. IN: *Zapret na zhizn'* [Ban on life]. Kazan: Tatar. kn. izd-vo, 1993, pp. 42-60.

Mukhametdinova A. Kh. *Hadi Atlasi kak istorik: dis. ... kand ist. nauk* [Khadi Atlasi as a historian: dis. ... Cand. of History]. Kazan, 2003, 149 p.

Seber tarihy; Soen-bike; Kazan hanlygy: Tarihi eserler. [History of Siberia; Soen-Bike; Kazan Khanate: Historical Works]. Kazan: Tatar. Kit. Publishing House, 1992, 448 p.

Sultanbekov B. F. *"Delo" Hadi Atlasova: v kontekste politicheskoj atmosfery 30-h godov* ["The Case" of Khadi Atlasov: in the Context of the Political Atmosphere of the 1930s]. IN: *Pervaya zhertva Genseka. Mirsaid Sultan-Galiev: Sud'ba. Lyudi. Vremya* [The First Victim of the General Secretary. Mirsaid Sultan-Galiev: Fate. People. Time]. Kazan: Tatar. book publ., 1991, pp. 72-99.

Һadi Atlasi: *Tarihi dokumental' zhyentyk* [Minnullin R., Mukhametdinova A., Hadiev I. (ed. by) Khadi Atlasi: Historical documentary collection]. Kazan: Zyen publ., 2007, 400 p.

Сведения об авторе

Багаутдинова Халида Зиннатовна, научный сотрудник Института истории им. Ш. Марджани АН РТ; ORCID: https://orcid.org/0009-0009-1809-8556; e-mail: halida12_61@mail.ru

About the author

Khalida Z. Bagautdinova, Researcher at the Institute of History named after Sh. Marjani of the Academy of Sciences of the Republic of Tatarstan; ORCID: https://orcid.org/0009-0009-1809-8556, e-mail: halida12_61@mail.ru

В редакцию статья поступила 15.07.2026, опубликована:

Баһаветдинова Х. З. Хатлар – тормыш көзгесе: Һади Атласи һәм аның нәсел варислары (Һ. Атласиның тууына 150 ел тулу уңаеннан) // Гасырлар авазы – Эхо веков Echo of centuries. – 2026. – № 4. – С. 91-104.

Submitted on 15.07.2026, published:

Bagautdinova Kh. Z. Khatlar – tormysh kozgese: Һadi Atlasi hem anyn nesel varislary (Һ. Atlasinyn tuuyna 150 el tulu unaennan) [Letters as a Mirror of Life: Khadi Atlasi and His Descendants (on the occasion of the 150th anniversary of Kh. Atlasi's bith)]. IN: *Gasyrlar avazy – Eho vekov* [Echo of centuries], 2026, no. 4, pp. 91-104.